# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең Тугаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2025 ел 10 ноябрь** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең Уставының 14 статьясына ярашлы рәвештә, түбәндәге сорау буенча 2025 нче елның 10 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Сез 2026 нчы елда, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең Тугаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, 1 төркем инвалидлардан, Әфганстанда (ДРА) хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, локаль конфликтларда (Чечня) хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан тыш, алар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә һәм үзара салым түләүдән гражданнар-контрактчыларны, СВО зонасында хезмәт итүче гражданнар һәм өлешчә мобилизация буенча чакырылган гражданнарны, шулай ук балигъ булган балаларын, хатынын, алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарын түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

**I. Урамны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:**

1) Урам яктыртуын тәэмин итү, ремонтлау
2) Материаллар сатып алу

**II. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:**

1) Скважинаны бораулау
2) Материаллар сатып алу
3) Су сыйфатының анализын үткәрү

**III. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:**

1) Янгын сүндерү машинасын карап тоту

**IV. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту**:

1) Юлларны карап тоту - җәйге чорда
2) Юлларны карап тоту - кышкы чорда
3) Вахитов, Пушкин урамнары юлын төзекләндерү һәм ремонт өчен кирәкле материаллар сатып алу

**V. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонт, коймалар төзү:**

1) Каты коммуналь калдыкларны чыгарту
2) Зиратта үлән чабу
3) Печән чапкыч машина өчен бензин сатып алу

**VI. Торак пунктның бүтән территорияләрен төзекләндерү:**

1) Массакүләм чаралар урынын төзекләндерү, материаллар сатып алу
2) Үләннәрне чабу, печән чапкычлар сатып алу

**«РИЗА»** **«КАРШЫ»**

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 163 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 95 кеше, бу 58,2% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 95 кеше тавыш бирде; 0 кеше "КАРШЫ" позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлеге Тугаш торак пунктында халык җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. 2026 нчы елда, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең Тугаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, 1 төркем инвалидлардан, Әфганстанда (ДРА) хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, локаль конфликтларда (Чечня) хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан тыш, алар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә һәм үзара салым түләүдән гражданнар-контрактчыларны, СВО зонасында хезмәт итүче гражданнар һәм өлешчә мобилизация буенча чакырылган гражданнарны, шулай ук балигъ булган балаларын, хатынын, алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.

3.Түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

**I. Урамны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:**

1) Урам яктыртуын тәэмин итү, ремонтлау
2) Материаллар сатып алу

**II. Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:**

1) Скважинаны бораулау
2) Материаллар сатып алу
3) Су сыйфатының анализын үткәрү

**III. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:**

1) Янгын сүндерү машинасын карап тоту

**IV. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту**:

1) Юлларны карап тоту - җәйге чорда
2) Юлларны карап тоту - кышкы чорда
3) Вахитов, Пушкин урамнары юлын төзекләндерү һәм ремонт өчен кирәкле материаллар сатып алу

**V. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонт, коймалар төзү:**

1) Каты коммуналь калдыкларны чыгарту
2) Зиратта үлән чабу
3) Печән чапкыч машина өчен бензин сатып алу

**VI. Торак пунктның бүтән территорияләрен төзекләндерү:**

1) Массакүләм чаралар урынын төзекләндерү, материаллар сатып алу
2) Үләннәрне чабу, печән чапкычлар сатып алу

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Түбән Табын авыл җирлеге башлыгы** **Р.Ш. Кыяметдинов**